БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 09 2023 ел № 252

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча 2023 елның IV кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен раслау турында

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2023 елның 23 августындагы 237 номерлы «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» БП (бәйсез партнерлык) эксперт-консультация советы хаты һәм Балтач муниципаль районының 2023 елның 15 сентябрендәге 11 номерлы торак комиссиясе карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында Балтач муниципаль районы территориясендә 2023 елның IV кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 32 524 сум сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов